ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУЕМБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

2019 елның 28 ноябре №22

«Җир салымы турында» 2013 елның
22 ноябрендәге 32 номерлы
Туембаш авыл җирлеге Советы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Туембаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 32 номерлы Туембаш авыл җирлеге Советы карарына (Туембаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 36 номерлы, 2015 елның 27 маендагы 22 номерлы, 2015 елның 17 ноябрендәге 12 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 13 номерлы, 2018 елның 07 ноябрендәге 31 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 34 номерлы, 2018 елның 18 декабрендәге 36 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) кадастр бәясеннән 0,1 процент – торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары билгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешләрдән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә карата;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Туембаш авылы җирлеге торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән соң кимендә бер ай узгач, үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: И. Ф.Гарипов